РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.03.2019 №51-п

Саба муниципаль районы халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу тәртибе турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә Россия Федерациясендә мәгълүмат җыю һәм алмашу тәртибе турында» 1997 елның 24 мартындагы 334 номерлы карары нигезендә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, фаразлана торган һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында халыкка үз вакытында хәбәр итү чараларын оператив кабул итү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу Тәртибен расларга.

2. Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан Министрлык һәм ведомстволарның территориаль вәкиллекләренә, җирле үзидарә органнарына, предприятие, оешма җитәкчеләренә, милек формасына бәйсез рәвештә, «Саба муниципаль районы граждannar саклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://saby.tatarstan.ru адресы буенча Саба муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Р.Н. Минниханов

РАСЛАНДЫ
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башлыгының
25.03.2019 № 51-п
карары белән

**Саба муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашу Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Саба муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм алмашуның төп кагыйдәләрен билгели (алга таба - мәгълүмат).

Мәгълүматта табигать һәм техноген характердагы фаразланган һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр һәм аларның нәтиҗәләре турында; тиешле территорияләрдә радиацион, химик, медик-биологик, шартлау, янгын һәм экологик куркынычсызлык турында белешмәләр, шулай ук, милек формасына бәйсез рәвештә, Саба муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары (алга таба - оешмалар), җирле үзидарә органнарының бу өлкәдә эшчәнлеге турында белешмәләр булырга тиеш.

2. Мәгълүмат җыю һәм алмашу табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү (алга таба - гадәттән тыш хәлләр) чараларын күрү, шулай ук фаразланган һәм барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында халыкка үз вакытында хәбәр итү максатларында, оешмалар, җирле үзидарә органнары, Саба муниципаль районы башкарма комитеты, дежур-диспетчерлык хезмәтләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының җирле үзидарә органнары, Саба муниципаль районының башка структур бүлекчәләре мәгълүмат җыю һәм алмашуны халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче органнар - Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба - Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) һәм Татарстан Республикасы Саба районы гражданнар саклау идарәсе (алга таба - гражданнар саклау идарәсе) аша гамәлгә ашыралар.

4. Саба районы гражданнар саклау идарәсе:

- мәгълүмат җыю һәм алмашу эшен җайга сала (координацияли);

- Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан әйләнә-тирә табигый мохитнең торышын, потенциаль куркыныч объектларда һәм алар янындагы территорияләрдәге хәлләрнең торышын күзәтүче һәм контрольдә тотучы федераль буйсынудагы структур органнар тарафыннан, Саба муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган мәгълүматны җыюны һәм эшкәртүне гамәлгә ашыра.

- Саба муниципаль районы башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклауның торышы турында еллык доклад өчен мәгълүмат бирә;

- гадәттән тыш хәлләрнең исәбен алып бара.

5. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге мәгълүмат түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

- гадәттән тыш хәлләр куркынычы (фаразы) һәм аларның мөмкин булган нәтиҗәләре турында;

- радиацион, химик, медик-биологик, шартлау, янгын һәм экологик куркынычсызлык торышы турында;

- гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү һәм аның үсүен кисәтү буенча тәкъдим ителгән чаралар турында;

- гадәттән тыш хәлләр фактлары һәм аларның төп параметрлары турында;

- гадәттән тыш хәлләр зоналарында халыкны һәм территорияләрне яклау чаралары, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр алып бару турында;

- оешмаларның эшчәнлек характеры һәм аларның потенциаль куркынычлыгы турында.

6. Мәгълүмат барлык гамәлдәге каналлар һәм элемтә төрләре, шул исәптән электрон почта аша да бирелергә мөмкин.

7. Гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы һәм фактлары турында гадәттән тыш хәбәр Саба муниципаль районының гражданлык саклау идарәсенә дежур-диспетчерлык хезмәтләре тарафыннан кичекмәстән аларның карамагында булган теләсә нинди элемтә чараларын кулланып тапшырыла.

8. Гадәттән тыш хәлләр фактлары турында язмача раслама, шулай ук ашыгыч һәм агымдагы белдермә (хәбәр) идарә итү органнарының тиешле җитәкчеләре яки аларга билгеләнгән тәртиптә имза салу хокукы бирелгән вазыйфаи затлар имзасы белән тапшырыла.

9. Муниципаль район буенча гражданнарны яклау идарәсенә үзара бәйләнештә булган идарә органнарыннан аларның компетенциясе чикләрендә һәм мәгълүмат сорау һәм алу хокукы бирелә.

10. Муниципаль район буенча гражданнар яклау идарәсенең оператив кизү торучысы гадәттән тыш хәл турында мәгълүмат алган очракта, аны Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының оператив дежур хезмәтенә телефон аша, Саба муниципаль районының гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы комиссиясе рәисенә, министрлыкларның һәм ведомстволарның территориаль вәкиллекләренә, шулай ук, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының һәм якын-тирә районнарның идарәләренә тапшыра.

# Татарстан Республикасы
# Саба муниципаль районының хәбәр итү
# СХЕМАСЫ

